**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия турында» 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 13 мартындагы ПУ-271 номерлы, 2015 елның 28 мартындагы ПУ-372 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-505 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-370, 2022 елның 9 апрелендәге 257 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 3 апрелендәге 196 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәдә:

3.1 пунктның алтынчы абзацында «, шул исәптән килешү нигезендә дә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.16 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан Р.Р. Амановны, Р.Г. Гаффаровны, И.Р. Метшинны чыгарырга;

Комиссия әгъзасы А.В. Артемьевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Су ресурслары федераль агентлыгы Түбән Идел су бассейны идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге башлыгы (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 05 апрель
№ 268